ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.105, с.Нижние Чершилы,
Лениногорский район, 423296
Тел.: (85595) 3-95-67, факс 3-95-66
E-mail: Ncher.Len@tatar.ru
ИНН 1649012890 КПП 164901001
ОГРН 1061689013154

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Үзәк урамы, 105 нче йорт,
Түбән Чыршылы авылы,
Лениногорск районы, 423296
Тел.: (85595) 3-95-67,
факс 3-95-66
E-mail: Ncher.Len@tatar.ru
ИНН 1649012890 КПП 164901001
ОГРН 1061689013154

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 7

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1. Урам утларына техник хезмәт күрсәтү.
2. Юлларны һәм күперләрне карап тоту( юлларны кардан чистарту).
3. Агачлар кисү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урамы, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында-Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урамы, 23нче йорт янында, «АФ-Спартак» ҖЧҖ идарәсе бинасында-Совет урамы, 2нче йорт , Югары Чыршылы авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27нче йорт, Мордва Ивановкасы авылында-Совет урамы, 13нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина